РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел.: (84360) 2-11-89 (факс),
E-mail: Telache@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

422080, Teләче авылы, Ленин урамы, 46,
тел.: (84360) 2-11-89 (факс)
E-mail: Telache@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 57 «30» июля 2012г.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы хакында

"Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында" 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, "Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елнын 30 декабрендәге 794 номерлы карары, "Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында теләсә кайсы челтәрдән һәм элемтә чараларыннан өстенлекле файдалану, шулай ук аларны туктатып тору яисә чикләү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 31 декабрендәге 895 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп туганда һәм килеп чыкканда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасын камилләштерү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә (А.Г. Мирсаетов) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкына гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне оештыру функцияләрен координацияләүне гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Теләче муниципаль районы буенча идарәсенә, Теләче РЭЭТ, Арча ЗЭЭТ, Россия ЭЭМ Теләче муниципаль районынын «Саба» ПБ җитәкчеләренә әлеге карар белән шәхси составны таныштырырга, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында халыкка мәгълүмат бирү системасы турындагы нигезләмәне үтәүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

И. Ф. Зарипов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БУЛЕГЕ

Кушымта
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башлыгының
«30» июль 2019 ел № 57
номерлы карары нигезендә
расланган

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы яисә әлеге хәлләр килеп чыгуы турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасы турында

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 69 - ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге № 794 номерлы, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында элемтә һәм чараларның теләсә нинди челтәрен һәм чараларын куллануны өстенлекле файдалану, туктатып тору яисә чикләү турында» 2004 елның 31 декабрендәге № 895 номерлы карарлары нигезендә эшләнелгән һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы турында халыкк сөйләм формасында хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибен билгели.

1.2. Гадәттән тыш хәлләр туганда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү максатларында, ведомство һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, оешмаларның яңгыравыклы сөйләүче күчмә һәм стационар җайланмалары кулланыла.

1.3. Яңгыравыклы җайланмалардан файдалану хокукы бирелә:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба текст буенча- район ГТХЯК);

1.4. Сөйләм хәбәрләре алдан ук әзерләнергә һәм хәбәр бирүче объектларда сакланырга тиеш.

## 2. Хәбәр итү системаларының структурасы һәм бурычлары

2.1. Хәбәр итү системасы үз эченә район хәбәр итү системасын, потенциаль куркыныч объектларны урнаштыру районнарында локаль хәбәр итү системаларын һәм җитештерү, социаль өлкә предприятиеләренә хәбәр итү системасын (хәбәр итүнең объектлы системалары) ала.

2.2. Район хәбәр итү системасының төп бурычы булып гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының район звеносы һәм гражданнар оборонасы формированиеләре белән идарә итүне гамәлгә ашыручы

органнарга хәбәр итү (күрсәтмәләр) һәм ашыгыч мәгълүмат сигналларын түбәндәгеләргә җиткерүне тәэмин итү тора:

- икътисад объектлары җитәкчеләренә;

-тормышны тәэмин итә торган объектларның диспетчырлык хезмәтләренә;

- район территориясендә яшәүче халыкка.

2.3. Хәбәрләрнең локаль системаларының төп бурычы - хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны түбәндәгеләргә җиткерүне тәэмин итү:

- объектның җитәкчеләренә һәм персоналларына;

- объектлы штаттан тыш булган формированиеләргә;

- локаль хәбәр итү системасы эшчәнлеге зонасында урнашкан җитештерү һәм социаль өлкә объектлары җитәкчеләренә;

- БДДХ;

- локаль хәбәр итү системасы гамәлдә булган зонада, потенциаль куркыныч объектка турыдан-туры якында яшәүче халык.

2.4. Объект системасының төп бурычы булып сигналларны һәм мәгълүматны түбәндәгеләргә җиткерү тора:

- объектның җитәкчеләре һәм персоналы;

- объектлы көчләр һәм хезмәт күрсәтүләр.

2.5. Барлык дәрәҗәләрдәге хәбәр итү системалары халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән, шулай ук хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге гамәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан саклау бурычларын гамәлгә ашыру максатларында кулланыла.

2.6. Хәбәр итү системаларын урнаштыру автоматлаштырылган булмаган ысул белән башкарыла. Барлык дәрәҗәләрдәге хәбәр итү системасы эше вакытында хәбәр итүнең төп ысулы - автоматлаштырылмаган ысул.

2.7. Автоматлаштырылмаган хәбәр итү ысулы белән сигналларны һәм мәгълүматны җиткергәндә түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

- махсус хәбәр итү аппаратурасын кулланмыйча, ведомство элемтә каналлары, гомуми файдаланудагы элемтә челтәре буенча.

2.8. Сигналлар һәм мәгълүмат тапшыру өчен районда хәбәр итү системасы булдырыла, ул тәэмин итәргә тиеш:

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының район звеносына, гражданнар оборонасының җитәкче составына, районның ГО һәм ГТХ эшләре, икътисад объектлары идарәсе органнарының вазыйфаи затларына хәбәр итү;

“Игътибар! Барыгызга да!", районның бөтен территориясенә яисә аерым сайлап алынган икътисадый объектларга электросирена кертү;

- ГОГТХ идарә органнарына, районның оператив хезмәтләренә, командаларына, идарәнең һәм ашыгыч мәгълүматның сигналларын җиткерү;

- район идарә органнарына, формированиеләренә, халкына сөйләм мәгълүматын ашыгыч рәвештә җиткерү өчен радиотапшырулар каналларын тотып алу.

## 3. Белдерү системаларын барлыкка китерү, камилләштерү һәм һәрвакыт әзерлектә тоту тәртибе.

3.1. Хәбәр итү системалары вакытыннан алда төзелә.

3.2. Район һәм объект хәбәр итү системалары Теләче муниципаль районы Башлыгы, икътисад объектлары җитәкчеләре җитәкчелегендә, хәбәр итү һәм элемтә хезмәте, Теләче муниципаль районының ГТХЯКК катнашында булдырыла, камилләштерелә һәм һәрвакыт әзерлектә тотыла.

3.3. Потенциаль куркыныч объектларны урнаштыру районнарында, локаль хәбәр итү системалары, объектның тиешле җитәкчесе җитәкчелегендә һәм объектларның хәбәр итү һәм элемтә хезмәтләрен җәлеп итеп, даими әзерлектә булдырыла һәм тәэмин ителә.

3.4. Район, локаль һәм объектлы хәбәр итү системалары республика территориаль хәбәр итү системасының состав өлеше булып торалар һәм әлеге система белән оештыру, техник, программа ягыннан үзара бәйләнгән булырга тиеш.

3.5. Теләче муниципаль районының  Теләче РЭЭТ гражданнар оборонасы идарәсе, икътисад объектлары хәбәр итү системаларын санкцияләнмәгән эшкә катнаштыруны булдырмау буенча оештыру-техник чаралар комплексын үткәрә.

3.6. Хәбәр итү системасының тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатларында, аны төзегәндә мобиль хәбәр итү чаралары запасларын булдыру һәм алардан файдалану күздә тотыла.

3.7. Хәбәр итү системаларының әзерлегенә ярдәм итү максатларында аларның эшкә әзерлеген тикшерәләр һәм эксплуатация-техник хезмәт күрсәтү оештыралар.

3.8. Теләче районы ГТХЯК комиссиясе, тиешле орган җитәкчесенең карары һәм расланган тикшерүләр планы нигезендә, хәбәр итү системаларын планлаштыра һәм тикшерә.

3.9. Хәбәр итү чараларына эксплуатацион-техник хезмәт күрсәтү ГОГТХ эшләре буенча органнар тарафыннан оештырыла һәм элемтә предприятиеләре белән килешү шартларында үткәрелә

4. Хәбәр итү системаларын җәлеп итү.

4.1. Хәбәр итү системасын эшкә җигү турында карарны Теләче муниципаль районы Башлыгы (икътисад объекты җитәкчесе) яки аны алыштыручы зат кабул итә.

4.2. ДДХ сигналлар (күрсәтмәләр) һәм хәбәр итү мәгълүматын, барлык элемтә һәм хәбәр итү чараларын кулланып, чираттан тыш рәвештә тапшыра.

4.3. Россия ЭЭМ «Саба» Теләче районы оператив дежурные, икътисад объектларының дежур - диспетчерлык хезмәтләре сигналлар (күрсәтмәләр) яки хәбәр итү мәгълүматын алалар, хәбәрдар булуларын раслыйлар һәм алардагы белдерү буенча инструкцияләр нигезендә эш итәләр.

4.4. Сигналлар һәм халыкка хәбәр итү өчен радио, телевизион һәм чыбыклы тапшырулар челтәрләре, нинди ведомствога каравына, оештыру - хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, программаларны трансляцияләү, гамәлдәге законнар нигезендә, өзелергә мөмкин.

4.5. Район территориясендә радиотрансляция челтәрләре, радиотапшырулар һәм телевизион станцияләр (милек формаларына бәйсез рәвештә) тапшырулар тапшыруны трансляцияләүне туктатып, ДДХ, Теләче районы Башлыгы (аны

алмаштыручы затлар) командасы буенча гына гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү өчен эшли.

4.6. Сөйләм мәгълүматы, халыкка тапшырулар программаларының биш минуттан да артмаган тәнәфес вакыты аралыгында бирелә, сөйләм хәбәрләрен тапшыру вакытында ике, өч тапкыр кабатлау рөхсәт ителә.

4.7. Хәбәр итү системасын җәлеп итү тәртибе, хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Теләче муниципаль районы Башлыгы, икътисад объекты җитәкчесе карары белән билгеләнә.

4.8. Хәбәр итү системаларын (санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән) җәлеп итүнең барлык очраклары турында ГО һәм ГТХ эшләре буенча идарәнең югарырак органына хәбәр ителә.

## 5. Хәбәр итү сигналлары.

5.1. Хәбәр итү сигналы - хәбәр итү системасы буенча тапшырыла торган һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының район звеносы хезмәтләре һәм көчләре белән идарә итүче органнар тарафыннан гражданнар оборонасының штаттан тыш һәлакәт-коткару формированиеләре һәм халык тарафыннан билгеле бер чаралар уздыру өчен команда булып торучы шартлы сигнал.

5.2. Җирлеккә хәбәр итү өчен, бердәм сигнал билгеләнгән: "ИГЪТИБАР! БАРЫГЫЗГА ДА!"

5.3. Авария хәлендәге химик куркыныч матдәләр (АХХКМ) белән зарарлану һәм халык өчен куркыныч булган башка эре аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәләре турында сигнал, АХХКМ ташу (агу) белән булган зур аварияләр һәм һәлакәтләр куркынычы очрагында бирелә.

Сигнал бирү өчен барлык район элемтә һәм хәбәр итү техник чаралары файдаланыла. Сигнал, билгеләнгән тавыш, яктылык һәм башка билгеләр бирү белән, кабатлана. Бу сигнал буенча Теләче муниципаль районының гражданнар оборонасы идарәсе күрсәтмәләре нигезендә эш итәргә кирәк.

5.4. Су басу (су керү) куркынычы турында сигнал гидротехник корылманы бозу яки турыдан-туры бозу куркынычы булганда бирелә. Су басу (су керү) мөмкинлеге зонасында яшәүче халык хәбәр итүнең локаль системалары, үткәргеч радиотапшырулар һәм телевидение челтәрләре буенча сөйләм хәбәрләрен күп тапкырлар тапшыру юлы белән хәбәр ителә.

5.5. Хәбәр итү сигналларын бирү, районның барлык территориясендә яисә сайлап алынган җитештерү һәм иҗтимагый объектларында, үзәкләштерелгән кушуны кулланып, бердәм "Игътибар! Барыгызга да!" билгесе аша оештырыла, ягъни радиотрансляция, радиотапшыру һәм телевидение каналлары буенча тыныч һәм хәрби вакытның мөмкин булган яки килеп чыккан гадәттән тыш хәлләре турында мәгълүмат җиткереп, бердәм сигнал бирү.

## 6. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының район звеносы һәм гражданнар оборонасының штаттан тыш формированиеләре

көчләре белән идарә итүне гамәлгә ашыручы җитәкче составына, органнарына хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе.

6.1. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының район звеносы һәм штаттан тыш авария-коткару формированиеләре белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнарны әзерлеген җиткерү турында сигналлар (боерыклар) җиткерү үзәкләштерелгән хәбәр итүнең гамәлдәге системасы һәм районның элемтә системасының барлык булган каналлары аша, билгеләнгән тәртип буенча ДДХ гамәлгә ашырыла.

Идарәнең кул астындагы органнары сигналлар (күрсәтмәләр) алуны раслый һәм аларны үзенең җитәкчелек составына җиткерә.

6.2. Сигналлар (күрсәтмәләр) идарәнең тиешле дәрәҗәсендәге үзәкләштерелгән хәбәр итү системасы буенча, чираттан тыш, үзәкләштерелгән хәбәр итү системаларын кулланып, циркуляр һәм сайланулы (юнәлешләр буенча), район идарәсе пунктыннан тапшырыла.

6.3. "Химик куркыныч"ка хәбәр итү сигналын тапшыру Теләче муниципаль районы башлыгына (яки аны алмаштыручы затка) җиткерелә. Әлеге сигналны алу белән район халкы өчен хатлар текстларын хәбәр итү һәм тапшыру карарын Теләче районы Башлыгы кабул итә (радиация торышы фаразы мәгълүматлары буенча).

6.4. Гражданнар оборонасының җитәкче составына һәм хезмәтләренә, гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча идарә органнары шәхси составына хәбәр итү хезмәт һәм фатир телефоннары аша башкарыла; дежур хезмәтләре тарафыннан телефон, җибәрүле яки башка билгеләнгән сигналлар аша башкарыла.

7. Халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү тәртибе.

7.1. Гражданнар оборонасының ГО һәм ГТХ буенча җитәкчелек һәм хезмәт составына хәбәр итү, Теләче муниципаль районы Башлыгы карары нигезендә, эш һәм фатыйр телефоннары аша башкарыла; электросиренаны кушу юлы белән ("Игътибар! Барыгызга да!" сигналы), алга таба гамәлдәге чыбык, радио һәм телевизион тапшырулар челтәрләре буенча мәгълүмат җиткереп, дежур хезмәтләргә телефон, җибәрүле яки башка билгеләнгән сигналлар буенча турыдан-туры хәбәр итү рәвешендә.

7.2. Халыкка һәм эшли торган икътисадый объектларга хәбәр итү сигналларын кабатлау өчен локаль һәм объектлы хәбәр итү системалы, мобиль хәбәр итү чаралары, транспорт кычкыртулары кулланыла.

7.3. Оповещение о начале эвакуации населения организуется установленным порядком на объектах экономики руководителями данных объектов и руководителями жилищно-эксплуатационных органов.

7.4. Тыныч һәм сугыш вакытының гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең төп ысулы булып, ведомствога бәйсез рәвештә, радио һәм телевизион тапшырулар кулланып, сөйләм мәгълүматын тапшыру санала.

7.5. Халык игътибарын җәлеп итү өчен, сөйләм мәгълүматын тапшыру алдыннан электросирена, кычкыртулар һәм башка сигнал чараларын куллану үткәрелә, бу "Игътибар! Барыгызга да!" дигәнне аңлата.

Бу сигнал буенча халык, икътисад объектларының эшчеләре һәм хезмәткәрләре, ашыгыч хәбәрләрне тыңлау өчен, радио һәм телевизион кабул итү бүлмәләренә керергә тиеш.

Күрсәтелгән сигнал буенча, кичекмәстән хәбәр ителә торган территориядә урнашкан барлык тапшыру төеннәре, радиотапшырулар һәм телевизион студияләр мәгълүмат тапшыруга әзерләнелә, тышкы тавыш бирү челтәрләре кушыла, яңгыравыклы элемтә урнаштыру җайланмалары белән җиһазландырылган махсус машиналар җәлеп ителә.

7.6. Халыкка вакытында хәбәр җиткерү һәм халыкка мәгълүмат җиткерү өчен җаваплылык Теләче муниципаль районының гражданнар оборонасы идарәсенә йөкләнә.

7.7. Потенциаль куркыныч объектлар урнашкан районнарда халыкка хәбәр итү һәм хәбәр итү өчен локаль хәбәр итү системалары файдаланыла, алар потенциаль куркыныч объектларны һәм башка оешмаларны үз вакытында зонада яшәүче халыкка "Игътибар! Барыгызга да!" сигналын һәм гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы турында, шулай ук вакыйгаларны үстерелеше һәм алга таба гамәлләр буенча тәкъдимнәр турында мәгълүмат җиткерү өчен билгеләнгән.

## 8. Татарстан Республикасының Теләче муниципаль районы буенча ГО һәм ГТХ министрлыгы идарәсенең, Теләче РЭЭТ ның, Арча ЗЭЭТ ның, җирле телевидение һәм радионың халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү буенча бурычлары

8.1 Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы буенча ГО һәм ГТХ эшләре министрлыгы идарәсе:

- халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү өчен сөйләм хәбәрләре текстларын эшли һәм аларны кәгазь һәм магнит чыганакларда язып алуны оештыра;
- диспетчерлар әзерләүне оештыра БДДХ-01;
- Арча ЗЭЭТы, муниципаль телевидение һәм радио белән берлектә халыкка хәбәр итү системаларын тикшерүне, сигналлар һәм мәгълүмат бирү буенча тренировкалар уздыруны планлаштыра һәм үткәрә;
- сигналлар һәм хәбәр итү челтәрләре буенча мәгълүмат биргәндә тиешле оператив дежур хезмәтләренең үзара хезмәттәшлек итү тәртибе турында документлар эшли.

8.2. Арча ЗЭЭТ ның Теләче РЭЭТ:

- сигналлар һәм хәбәр итү мәгълүматын җиткерү өчен кулланыла торган техник хәбәр итү чараларының, элемтә каналларының һәм тапшыру системаларының әзерлеген тәэмин итә;
- дежур тору хезмәтләрен оештыралар һәм әзерлиләр;
- элемтә объектларының эксплуатация-техник персоналын әзерлиләр.

8.3. Җирле телевидение һәм радио:

- хәбәр итү һәм сөйләм мәгълүматы сигналларын тапшыруга техник чараларның даими әзерлеген тәэмин итәләр;
- Теләче муниципаль районы гражданнар оборонасы идарәсе мөрәҗәгатьләре буенча, халык өчен, магнит чыганакларына сөйләм хәбәрләрен яздыра;
- хәбәрләр тапшыру объектлары персоналының халыкка хәбәр итүгә һәм мәгълүмат җиткерүгә даими әзерлеген тәэмин итәләр.

9. Хәбәр итү оешмалары җитәкчелеге.

9.1. Гадәттән тыш хәлләр янаганда һәм килеп туган очракта хәбәр итүне оештыруда гомуми җитәкчелекне Теләче муниципаль районы Башлыгы, Теләче муниципаль районы гражданнар оборонасы идарәсе, хәбәр итү һәм элемтә хезмәте, Теләче муниципаль районы ГТХЯКК аша, башкара.

10. Хәбәр итү системаларын финанслау тәртибе.

10.1. Хәбәр итү системаларын булдыруны, камилләштерүне (реконструкцияләүне) һәм эксплуатацияләүне, идарәнең барлык дәрәҗәләренә хәбәр итүнең мобиль чаралары запасларын булдыруны һәм тотуны финанслау федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.